| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

от 20.11.2020 г. Казань

**КАРАР**

№ 252-85/кс-2020

«ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ЖЧЖ) өчен, әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, эчә торган суга һәм ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ЖЧЖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2021-2025 елларга, әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ЖЧЖ ирекле файдаланылырга тиешле

мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2020 № 252-85/кс-2020
карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Питрәч муниципаль районы | | | |
| 1 | «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ҖЧҖ* | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 25,15 | 25,98 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 26,19 | 27,01 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 26,02 | 27,01 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 26,02 | 27,14 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 26,02 | 27,14 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 26,76 | 28,24 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 26,76 | 28,24 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 26,79 | 28,41 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 26,79 | 28,41 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 27,54 | 29,54 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2020 № 252-85/кс-2020
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ҖЧҖ | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2021 | 2959,79 | X | - | 0,81 |
| | | 2022 | X | 1 | - | 0,81 |
| | | 2023 | X | 1 | - | 0,81 |
| | | 2024 | X | 1 | - | 0,81 |
| | | 2025 | X | 1 | - | 0,81 |
| 1.2 | Су агызу | 2021 | 3886,90 | X | - | 0,81 |
| | | 2022 | X | 1 | - | 0,81 |
| | | 2023 | X | 1 | - | 0,81 |
| | | 2024 | X | 1 | - | 0,81 |
| | | 2025 | X | 1 | - | 0,81 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге